РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы, Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

17 январь 2019 ел №2

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 февралендәге 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алуы, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 15.01.2019 № 02-08-02-9-19 протесты нигезендә Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе турында" 19.02.2014елгы 9 нчы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен "даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak бастырып чыгарырга.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н. Н. Заһидуллин